Алдый алмас мине түбән ләззәт,
Вак тормышның  чуар пәрдәсе.
Шигыремдәге чынлык, ут һәм сөю-
Яшәвемнең бөтен мәгънәсе.

М.Җәлил.

# “Җырым аша белсен халкым”
# Ф.Кәрим



Совет чоры татар поэзиясенең күренекле вәкиле Фатих Кәрим (Фатих Әхмәтвәли улы Кәримов) 1909 елның 9 гыйнварында Россиянең элекке Уфа губернасы Бәләбәй өязе (хәзерге Башкортстан Республикасының Бишбүләк районы) Ает авылында мулла гаиләсендә туа. Мәктәпкә кергәнче үк укырга-язарга өйрәнә, аннан авыл мәктәбенең ике сыйныфын тәмамлый. 1922 елда абыйсы Габдулла Кәримов (шагыйрь Ярлы Кәрим, 1901–1937) аны үзе белән Бәләбәй шәһәренә алып китә һәм педагогия техникумының әзерлек сыйныфына укырга урнаштыра. Монда ике ел укып, әзерлек курсын тәмамлагач (1924), шул ук абыйсы ярдәмендә Казанга килеп, бер ел яшүсмер балалар йортында тәрбияләнә. 1925–1929 елларда Казан җир төзелеше техникумында укый.

Әдәби иҗат эше белән җитди шөгыльләнә башлавы да шушы студентлык елларына карый. 1926 елдан республика газеталарында яшь каләм тибрәтүченең көндәлек яшьләр тормышына багышланган мәкаләләре, фельетоннары, соңга таба балалар өчен хикәяләре һәм шигырьләре күренә башлый.

1931елда Ф.Кәримнең беренче китабы басылып чыга.Ул “Яшь ленинчы” (хәзерге “ Сабантуй”)газетасы редакциясендә, китап нәшриятында эшли.

Ул шигырьләр, поэмалар, хикәяләр, повестьлар һәм драма иҗат итә.

Сугыш бетәргә санаулы көннәр калганда, 1945 елның 19 февралендә, Көнчыгыш Пруссиядәге соңгы сугышларның берсендә утыз алты яшьлек шагыйрь дошман пулясыннан һәлак була.





Җир төзелеше техникумында укыганда булачак әдип ныклап әдәби һәм иҗтимагый эшчәнлеккә тартыла. А. Алиш, Г.Минский, М. Әмир һәм башка бик күп дуслар таба.

**Рәсемнәрдә Фатих Кәрим үзенең якын дуслары белән.**





**Әлеге шигырь авторның үз тормышы белән аваздаш. Ф.Кәрим сугышта әһәмиятле сугышчан бурыч үтәгәндә батырларча һәлак була. Ләкин шагыйрь халык күңелендә исән.**

Үләм икән, үкенечле түгел,
Бу үлемнең миңа килүе.
Бөек җыр ул – Бөек Ватан өчен
Сугыш кырларында үлүе.

Кыр казы-дикий гусь

Тирән-глубокий

Төнбоек-кувшинка

Түбәнәйтү-снизить

Ялкын-пламя

Дәһшәтле сугыш-страшная война

Дан даулап-добиваясь славы

Шаулар-зашумят



Каурый-
перышко

**Игътибарыгыз өчен зур рәхмәт...**